

Мордовиядә соңгы ике елда эшмәкәрлек олкәсендә хәл шактый яхшырды.
Бизнес-берләшмә белән эш, даими очрашулар, Мордовия житәкчелегенен эшмәкәрлек белән шәхси хезмәттәшлеге һәм проблемаларны оператив хәл итv нәтижәсендә тискәре тренд бозыла һәм тотрыклы vсеш башлана. 2022 елда эшмәкәрләр саны 20 меннән артып китте, vзмәшгуль гражданнар саны да артты. Республиканын кече һәм урта эшкуарлык предприятиеләрендә барлыгы 100 менгә якын кеше эшли.
Мондый унай нәтижәләр Россия эшкуарлыгы коненә багышланган «Үз эшендә ин яхшылар» бизнес-форумы кысаларында янгырады. Анда Мордовия Главасы Артём Здунов катнашты; ул республика бизнесын һонәри бәйрәмнәре белән котлады. «Есть такая работа - развивать свой бизнес, преображать нашу Родину - Россию, Мордовию. Есть такая профессия - давать людям возможность развиваться, давать рабочие места, отвечать за них, - приветствовал собравшихся руководитель республики. - Отрадно, что мы смогли переломить тренд снижения – в прошлом году у нас был Год предпринимательства, сейчас идет рост и по регистрации бизнеса, и по среднесписочной численности работающих. Это говорит о том, что мы - государство, предприниматели, органы надзора - нашли общий язык».
Артём Здунов бизнес-берләшмә белән даими турыдан-туры арала-шунын моһимлеген билгеләп vтте. Ул шулай ук тобәк эшкуарларына vз зонасында булган якташларына ярдәмнәре очен рәхмәт белдерде.
«Сораулар бик кvп, ихтыяжлар кvп, һәрвакыт шулай була. Ләкин безнен республикада булган консолидация хормәткә лаек. Остәвенә, беркемнән дә сорарга кирәкми - безнен очен моһим, бу сезнен йорәкләрегездә, коллективларыгызнын йорәкләрендә бәяләмә таба. Хезмәтегез очен, кыс-ка гына вакыт эчендә эшегезнен кvп юнәлешләрен vзгәртә алганыгыз очен, олешчә аларны хәрби икътисад рельс-ларына кvчергәнегез очен рәхмәт. Без хәзер барыбыз да бер зур коймәдә,- дип ассызыклады республикабыз Главасы. - Региональ Хокvмәтнен бурычы - эшкуарларыбызнын сату базарларын кинәйтv - моны маркетплейслар, кvргәзмәләр, контрактлар тозvдә ярдәм итv, турыдан-туры эре корпорацияләр белән эшләv аша эшләргә момкин. Бизнес монда берvзе калырга тиеш тvгел».

Кон дәвамында «Кече һәм урта эшкуарлык» милли проекты кысаларында уздырыла торган «Үз эшендә ин яхшылар» бизнес-форумында, РМ Икътисад министрлыгы һәм «Минем бизнес» үзәге ярдәме белән, дүрт секция һәм 12 тармак мәйданчыгы, форумда катнашучылар күргәзмәсе эшләгән, эшлекле очрашулар, дискуссияләр һәм мастер-класслар узган. Форумда катнашучылар алдында Россия тобәкләреннән ин яхшы экспертлары чыгыш ясаган.
Форумда шулай ук «Мордовия Рес-публикасы эшкуары» республика конкурсына йомгак ясалган. Мордовия Главасы Артём Здунов жинүчеләрне һәм призерларны бүләкләгән. 2022 елда Мордовия Респуб-ликасынын ин яхшы эшкуары дип «Спрутс» компаниясе житәкчесе Александр Ширяев танылды. Жәмәгать туклануы олкәсендә ин яхшысы дип шәхси эшмәкәр Эльдар Рауф улы Долотказиннын «Tom Soy» дигән изакая-бары танылды.
Эльдар Рауф улы Долотказин 2019 елдан бирле бизнес олкәсендә эшли. Ул, бизнестагы һәр житәкче тосле, унышлар һәм унышсызлыклар кичергән. Беренче гомуми туклану ноктасын 2019 нчы елда, пандемиягә берничә ай калганда ача. Шул вакыт тормышыбыз нигездән үзгәрә. Кыска вакыт эчендә сис-теманы тулысынча үзгәртергә, кафе эшен башка юнәлешкә борып куярга туры килә ана; ин моһиме - бизнеска «батып китәргә» ирек бирмәскә.
Һәр эшкуар унышлы бизнес очен үз ачкычын эзли. Һәм кайвакыт, жину очен, күп авырлыкларны кичерергә туры килә. Эшмәкәр Эльдар Рауф улынын яшь эшмәкәрләргә киңәше: «Мин бирәчәк топ кинәш - хаталардан курыкмаска, чонки теләсә нинди хата артында киләчәктә кулланыла торган һәм файдага юнәлткән тәжрибә яшеренгән». Шуна да үткән ел житәкче һәм анын командасы унышларын билгеләп үткән иделәр инде. Изакая- бар «Ел ачышы» премиясен алды. Тырышлык нәтижәсен «Минем бизнес» үзәге хезмәткәрләре дә бәяләде, ә быел – жинүчеләр.
Бизнесмен Рауф улы Эльдар балачакта пешекче булып эшләргә теләгәнен таный. Бәлки нәкъ менә шушы хыял аны беренче ресторан ачуга китергәндер. Әмма, шулай да, уныш - учреждение идеясендә яшеренгән. Хәзер эшмәкәр һәм анын командасы бер урында торырга уйламый - алга атлый. Республиканын якын шәһәрләрендә тагын берничә нокта ачу планлаштырыла.

**Наилә НАСЫРОВА**